# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

“17” ноябрь 2021ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 17 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2021 елның 17 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2022 елда Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Таш-Чишмә авылы территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агач кисү, транспорт хезмәтләре күрсәтү, эш өчен түләү);
2) Авыл эчендәге куперне сүтеп, яңадан кору;

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыеның беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 254 (ике йөз илле дүрт) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 130 (йөз утыз) кеше, бу 51,18 % тәшкил итә..

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 130 (йөз утыз) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2022 елда Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Таш-Чишмә авылы территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агач кисү, транспорт хезмәтләре күрсәтү, эш өчен түләү);
2) Авыл эчендәге куперне сүтеп, яңадан кору;

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль

районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Өҗем авыл җирлеге башлыгы Вәлиев А.Т.